РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.12.2024 № 1122-п

2025-2030 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү муниципаль программасын раслау турында

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль юл фондын төзү турында» 2013елның 09 октябрендәге 216 номерлы Саба муниципаль районы Советы карары нигезендә һәм Саба муниципаль районының юл фонды акчаларыннан файдалану максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. 2025-2030 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү муниципаль программасын расларга.
2. «2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауның һәм аларның норматив торышына китерүнең муниципаль программасын раслау турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 22 декабрендәге 1989-п номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга
3. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә 2025-2030 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү муниципаль программасын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Э.Д. Рамазановка йөкләргә.

Җитәкче М. Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 26 декабрендәге 1122-п номерлы карары белән РАСЛАНГАН

**2025-2030 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү муниципаль программасы**

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программа исеме | 2025-2030 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү муниципаль программасы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| Программаның максатлары һәм чаралары | Программаның максаты-халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын күтәрү, Саба муниципаль районы торак пунктларының урам-юл инфраструктурасының тормыш эшчәнлеген җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын норматив халәткә китерү юлы белән тәэмин итү. |
| Программаның бурычлары | Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү планын эшләргә |
| Программаны гамәлгә ашыру срогы | 2025-2030 еллар |
| Программаның структурасы | каралмаган |
| Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 2025-2030 елларда 68.805, 200 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:<br>2025 ел-22 156,900 мең сум;<br>2026 ел-22 967,000 мең сум;<br>2027 ел-23 681,300 мең сум;<br>2028 ел-0,000 мең сум;<br>2029 ел-0,000 мең сум;<br>2030 ел-0,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында һәм Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (Чираттагы финанс елына һәм план чорына) Саба муниципаль районы бюджеты турындагы Карарына ярашлы рәвештә төгәлләштереләчәк.<br>Янга калган акчаларны ел саен юл хәрәкәте иминлеге чараларына җибәрергә. |
| Программаны гамәлгә ашыруның төп нәтиҗәләре | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы торак пунктларының урам-юл инфраструктурасының тулы канлы тормыш эшчәнлеге нигезендә район халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү.<br>Программаның нәтиҗәлелеге программа бүлекчәләрендә билгеләнгән максатчан күрсәткечләргә ирешү дәрәҗәсе буенча бәяләнә. |

## 1. Саба муниципаль районы торак пунктларының урам-юл инфраструктурасына характеристика

2025-2030 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программа (алга таба - Программа) Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль юл фондын төзү турында» 2013 елның 09 октябрендәге 216 номерлы карары нигезендә эшләнгән.

Саба муниципаль районы 1930 елда төзелгән, Татарстанның төньягында Кама алды – Кама алды икътисадый зонасының үзәк өлешендә урнашкан. Районның мәйданы 1098 кв.км, ул Татарстан Республикасының гомуми мәйданының 1,62%ын тәшкил итә. Унтугыз авыл һәм бер шәһәр җирлеге 67 торак пунктны берләштерә, халык саны 01.01.2016 елда 31736 кеше тәшкил иткән.

Район территориясе Мишә елгасы бассейнының өске өлешен алып тора. Нигездә бу-елга үзәннәре белән киң һәм сөзәк тезмәләргә бүленгән калкулыклы тигезлек, ә алар, чиратта, кечерәк елгаларның үзәннәре һәм вак үзәннәре белән ваграк икенчел тезмәләргә һәм сөзәк калкулыкларга бүленәләр.

Район үзәге – Б. Саба шәһәр тибындагы поселогы, республикабыз башкаласы Казаннан 98 чакрым ераклыкта, Шәмәрдән тимер юл станциясеннән 22 чакрым ераклыкта, Нократ Аланы пристаненнән 60 чакрым ераклыкта урнашкан.

Саба районы, Татарстан АССР составындагы административ-территориаль берәмлек буларак, 1930 елның 10 августында Бөтенрусия Үзәк сайлау комиссиясе карары белән оештырыла.

«Татарстан Республикасының Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлеге 2005 елның 31 гыйнварындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелде.

01.10.2024 ел торышы буенча гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының озынлыгы

1 нче таблица

| 01.10.2024 елгы хәл буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юллары | Барлыгы (км) | Озынлыгы (км), шул исәптән | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | ц / б | а/б | вак таш, чуерташ | грунт |
| Җирлекләрнең урам-юл челтәре | 342,89 | 0,13 | 152,07 | 138,69 | 51,99 |
| Норматив таләпләргә җавап бирми торган җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының озынлыгы | 51,99 км. - бу гомуми озынлыкның 15,16%ын тәшкил итә. | | | | |

Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларына хезмәт күрсәтүче оешмалар: «Саба ТКХ МПП» ААҖ, «Саба районының Шәмәрдән ТКХ МПП» ААҖ, «Рамазан»ҖЧҖ.

Автотранспорт предприятиеләре: «Яшен»ҖЧҖ.

Белем бирү учреждениеләрендә укучыларны йөртүче автотранспорт предприятиесе: «Яшен»ҖЧҖ. Мәктәп маршрутлары-37, мәктәп автобуслары – 24 берәмлек, гомуми белем бирү мәктәпләре саны - 21, шул исәптән урта мәктәпләр - 15, төп мәктәпләр - 6.

**2025-2030 елларда Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү**

2 нче таблица

| Каплау төре | 2024 | | 2025 | | 2026 | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | а/б | вак таш | а/б | вак таш | а/б | вак таш |
| Ремонт һәм норматив хәлгә китерү (км) | 4,81 | 5,36 | 3,92 | 4,69 | 3,66 | 3,94 |
| | 10,17 | | 8,61 | | 7,60 | |

## 2. Саба муниципаль районының юл инфраструктурасы сыйфатын үстерүнең институциональ проблемалары

Юл тармагы, икътисадый пространствоның состав өлеше буларак, транспорт-коммуникация системасын үстерүдә мөһим роль уйный, бу система шәһәр җирлегенең, авыл җирлекләренең һәм аерым торак пунктларның икътисады үсешенә дә, социаль өлкәсен яхшыртуга да актив йогынты ясый. Районның барлык икътисады кебек үк, юл тармагы да даими үсештә. Әмма юллар челтәренең үсеш темплары бүгенге заман таләпләренә җавап бирми. Автомобильләшү үсеше һәм юл челтәре үсеше арасындагы аерма бүген кискен характер алды.

Саба муниципаль районының юл инфраструктурасы сыйфатын үстерү проблемалары булып:

1. Үз-үзен тәэмин итүнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы (икъисадый, Финанс, социаль).

2. Юл хуҗалыгы объектларының техник паспортлары һәм аларны әзерләүгә финанс чаралары булмау.

3. Җирле бюджетларның керемнәре түбән булу һәм юл эшчәнлеген финанслауның җитәрлек булмавы.

Әлеге Программа югарыда аталган институциональ проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән.

## 3. Саба муниципаль районының юл инфраструктурасы сыйфатын арттыру өлкәсендәге проблемаларны хәл итүнең төп бурычлары

- Автомобиль юлларының гамәлдәге юл челтәрен һәм алардагы ясалма корылмаларны саклап калу һәм торгызу.
- Аларның транспорт-эксплуатация күрсәткечләрен автомобиль юлларыннан файдаланучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле дәрәҗәдә тәэмин итү.
- Ремонт һәм карап тоту эшләрен вакытында һәм сыйфатлы башкару.

## 4. 2024-2026 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү муниципаль программасының төп чаралары

3 нче таблица

| т/б № | Чараның исеме | Башкаручылар (килешү буенча) | Финанслау күләме һәм чыганаклары (мең сум) | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Смета документациясен эшләү | ТР Саба муниципаль районы җирлекләре башлыклары | Саба муниципаль районы бюджеты,<br>Барлыгы 68 805,200,<br>шул исәптән:<br>2025 ел – 22 156,900;<br>2026 ел - 22 967,000;<br>2027 ел - 23 681,300;<br>2028 ел - 0,000;<br>2029 ел - 0,000;<br>2030 ел - 0,000.<br>әлеге программаның 4 нче таблицасында күрсәтелгән финанс чараларын бүлү нигезендә | агымдагы елның апрель-март айлары |
| 2 | Смета документациясен тикшерү | "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының бердәм заказчы хезмәте" АҖ, ТР МФ Казначылык департаментының Саба районы территориаль бүлеге. | | тикшерүгә бирелгән көннән алып 1 нче атна эчендә |
| 3 | Ремонт эшләрен башкару | Ачык аукцион йомгаклары буенча электрон сатуларда җиңгән подряд оешмасы | | контрактта күрсәтелгән сроклар |
| 4 | Башкарылучы эшләрнең техник күзәтчелеге һәм сыйфатын тикшереп тору | "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының бердәм заказчы хезмәте" АҖ | | эшләр барышында |
| 5 | Башкарылган эшләрне кабул итү һәм объектны файдалануга тапшыру | Заказчы-объектның баланс тотучысы, Заказчы-төзүче - «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының бердәм заказчы хезмәте» АҖ | | ремонт эшләре тәмамлангач |

## 5. 2025-2030 елларда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауга юл фондының финанс чараларын бүлү

4 нче таблица

| № | Җирлекләр атамасы | Акчаларны еллар буенча бүлү (мең сумнарда) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 | 2030 |
| 1. | Саба шәһәр җирлеге | | 11 515,16 | | | | |
| 2. | Арташ авыл җирлеге | | | 3644,03 | | | |
| 3. | Олы Кибәче авыл җирлеге | | | | | | |
| 4. | Олы Нырты авыл җирлеге | | 3 897,08 | | | | |
| 5. | Олы Шыңар авыл җирлеге | 7 105,19 | | | | | |
| 6. | Курсабаш авыл җирлеге | | | 3683,16 | | | |
| 7. | Югары Симет авыл җирлеге | | | 3173,92 | | | |
| 8. | Явлаштау авыл җирлеге | | 4 107,41 | | | | |
| 9. | Эзмә авыл җирлеге | | | | | | |
| 10. | Иштуган авыл җирлеге | | | 4103,05 | | | |
| 11. | Килдебәк авыл җирлеге | | | | | | |
| 12. | Түбән Шытсу авыл җирлеге | | 3 447,35 | | | | |
| 13. | Мишә авыл җирлеге | | | | | | |
| 14. | Мичән авыл җирлеге | | | 4471,33 | | | |
| 15. | Сатыш авыл җирлеге | | | | | | |
| 16. | Иске Икшермә авыл җирлеге | | | 4605,81 | | | |
| 17. | Тимершык авыл җирлеге | 7 315,52 | | | | | |
| 18. | Шекше авыл җирлеге | | | | | | |
| 19. | Юлбат авыл җирлеге | | | | | | |
| 20. | Шәмәрдән авыл җирлеге | 7 736,19 | | | | | |
| | **БАРЛЫГЫ:** | **22 156,900** | **22 967,000** | **23 681,300** | **0,000** | **0,000** | **0,000** |